**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.11.2025

КАРАР
№ 1292

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 31 июлендәге 857 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 31 июлендәге 857 номерлы карарына (2025 елның 01 августындагы 860 номерлы, 2025 елның 21 августындагы 921/1 номерлы, 2025 елның 1 сентябрендәге 964 номерлы, 2025 елның 18 сентябрендәге 1044 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 сентябреннән 2025 елның 30 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга күрсәтелгән карар белән расланган бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибендә:

2 өлешнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләме - 50 000,00 (илле мең) сум 00 тиен.».

3.2 пункт. 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

«3.2. Бер мәртәбә түләү 18.11.2025-30.12.2025 аралыгында контракт төзегән гражданнарга бирелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин